Н. Т. S. S. Ç. Qazan LENIN isen
ӨLKӘ MASSA KITAPXANӘSE TӨP KITAP SAQLAV BYLEGE
ОСНОВНОЕ КНИГОХРАНИЛИЩЕ ОБЛАСТНОЙ МАССОВОЙ
им. ЛЕНИНА БИБЛИОТЕКИ АТССР г. Казань
Уг. К. № 27

ЧӘРШӘМБЕ
13 МАРТ
1940 ел
№ 60 (5860)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ТАТАРСТАН АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНЫҢ АРТТА КАЛУЫН БЕТЕРҮ ӨЧЕН

Татарстан партия оешмасы үзенең XXI нче өлкә конференциясенә халык хуҗалыгының барлык тармаклары буенча шактый уңышлар белән килде. Республикабызның промышленносте үсте, культура төзелеше күп тапкыр алга китте. Татарстан большевикларының сафлары бердәм, алар партиянең Үзәк Комитеты һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин тирәсенә тагын да ныграк, тагын да тыгызрак тупландылар.

XX нче һәм XXI нче Өлкә конференцияләре арасында Татарстанның авыл хуҗалыгы чәчү мәйданнарын техник һәм терлек азыгы культуралары чәчү хисабына киңәйтү, коллективлашуны үстерү, колхозларны һәм совхозларны техника белән коралландыруны арттыру, җәмагатьләштерелгән терлекчелекне үстерү буенча барды. Хәзер республикабыздагы хезмәт иясе крестьяннәрнең 94,6 проценты колхозларга берләшкән, барлык чәчү мәйданнарының 99,7 проценты колхозлар карамагында.

Әйе, колхозларның яхшы эшләүләре өчен, иген уңышын күтәрү өчен, терлекчелекне тагын да үстерү, аның продукция бирүен арттыру өчен бөтен нәрсә бар: җир, машина, алдынгы колхозларның бай тәҗрибәләре, гүзәл кадрлар һәм башкалар.

Шулай булуга да карамастан, Татарстанда 1939 нчы елны авыл хуҗалыгы эшләре канәгатьләнмәслек үтәлде. Без моны ВКП(б) Өлкә Комитетының эше турындагы отчеттан да ачык күрәбез.

Үткән елгы эш йомгаклары Татарстанда авыл хуҗалыгының төп һәм хәл иткеч тармаклар буенча артта калуын күрсәтәләр. Иң элек иген уңышының кимүе һәм, атларны исәпкә алмаганда, гомумән терлекләр санының кимүе турындагы хәлне ачык әйтергә һәм тиешле нәтиҗәләрне ясарга кирәк.

Республикабызның күп кенә колхозлары 1939 нчы елны иген уңышы планын бөртекле культуралар буенча да, техник культуралар буенча да үтәмәделәр. Техник культуралар уңышы буенча планның 50 проценты да үтәлмәде. Юртыш, Зөя, Юдино, Константиновка МТС лары кебек начар эшләүче 17 МТС тракторлар эше буенча дәүләт планын, 65 МТС комбайннар эше планын үтәмәде. Шуның аркасында Татарстан тракторлар белән эшләү буенча элекке еллардагы Союз күләмендәге алдынгылыгын югалтты.

Үткән ел иген уңышының планы үтәлмәүнең төп сәбәпләреннән берсе итеп колхоз строе байлыгының төп чыганагы булган җирнең гафу ителмәслек начар эшкәртелүен әйтергә кирәк. 1939 нчы елны язгы чәчү, пар сөрү, культивация ясау, туңга сөрү эшләре вактында үткәрелмәделәр. Җиргә ашламалар кертү планы да үтәлмәде. Урып-җыю 1 нче сентябрьгә кадәр тартылды, ә Питрәч һәм Югары Ослан кебек районнар игеннәрне урып-җыю эшен октябрьгә кадәр суздылар. Шулай итеп, язгы чәчү вактында башланган артта калучылык ел буена дәвам итте.

Димәк, үткән ел иген уңышының түбән булуы, башлыча авыл хуҗалыгы эшләренең канәгатьләнмәслек үтәлүеннән, колхозларга җитәкчелекнең конкрет булмавыннан, эштәге өзеклекләрне вактында бетерү өчен колхозчылар массасын большевикларча туплый алмаудан килеп чыкты.

Татнаркомзем һәм күп кенә район җир бүлекләре үз эшләрен әле дә яңа баштан корып җиткергәннәре юк, колхозларга җитәкчелек итүдә әле дә канцеляриячел-бюрократик метод яшәп килә, артта калып баручы районнарны һәм колхозларны өзеклектән чыгару өчен эшлекле чаралар күрелми. Колхозларга җитәкчелек итүдә Татнаркомземның һәм Татсовнаркомның кайбер җаваплы работниклары булдыксызлык күрсәттеләр, кайсы районның ничек эшләвен, кайсы районга нинди ярдәм күрсәтергә кирәклекне белмәделәр. Алар политик җитәкче булу, кимчелекләрне бетерү өчен большевикларча көрәшү урнына, артта калган настроение койрыгында сөйрәлделәр.

Иптәш Алемасов конференциядә ясаган отчет докладында авыл хуҗалыгы мәсьәләләре буенча Өлкә Комитетның һәм район партия комитетларының эшен дә каты тәнкыйть итте. Кайбер районнар эшендә яраксыз метод, зарарлы практика хөкем сөрә. Җир органнарына җитәкчелек итү урнына, райкомнар алар эшен үзләре башкаралар. Шуның аркасында җир бүлекләре һәм совет органнары колхозлар эше өчен җаваплы булудан, алар белән турыдан-туры эш итүдән читтә калалар.

Иптәш Алемасов ВКП(б) Өлкә Комитетының отчетында Татарстан авыл хуҗалыгының артталыгын бетерү өчен конкрет юллар күрсәтте. 1940 нчы елны күрше кардәш республикалар белән—Чувашстан һәм Мордовия белән ярышта алдынгылыкны тәэмин итү, договорда каралган барлык йөкләмәләрне тулысынча үтәү өчен барлык колхозчыларны, МТС һәм совхозларның барлык эшчеләрен язгы чәчүне большевистик хәзерлек белән каршы алуга тупларга кирәк.

Тракторларга, авыл хуҗалыгы инвентарена ремонт ясау, чәчүлек орлыкларын туплау, МТС ларга ягулык кайтарту, механизатор кадрлар хәзерләү, даими звенолар төзү һәм аларны практик эшкә кушу, җирле ашламалар җыю планын тулысынча үтәү эшләре иң кыска срок эчендә төгәлләнергә тиеш.

Артта калып баручы һәрбер колхоз буенча конкрет чаралар билгеләп, аларны язгы чәчүгә хәзерлектә үк алдынгылар сафына чыгару эше хәзер иң сугышчан бурычларның берсе. Һәрбер колхоз эшенә тирән анализ ясамыйча, колхозның хәлен җентекләп белмичә торып конкрет җитәкчелек итеп булмый. Шуның өчен дә колхозларга җитәкчелек итүдә кәгазьгә, сводкаларга карап эш итмәскә, берничә алдынгы колхозлар уңышы белән масаймаска, артта калучыларны онытмаска, бәлки алдынгылар тәҗрибәсен киң күләмдә уртаклашып, гомуми күтәрелешкә ирешергә, республикабызның алдынгылар сафына чыгуы өчен көрәшергә кирәк. Партия үзенең җитәкче работникларыннан, җир һәм совет органы җитәкчеләреннән әнә шуны таләп итә.

ВКП(б) ның Татарстан оешмасының XXI нче өлкә конференциясенә Бондюг районыннан катнашучы делегатлар. Сулдан уңга—А. В. Соколова, И. Ф. Ядовин, Б. Бәһаветтинов, И. Вәлеев һәм М. Хөсәенев иптәшләр.

И. Галиев фотосы.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

11 нче мартта безнең частьләр Выборгны чолгап алуны тәмам иттеләр һәм шәһәрнең көнчыгыш һәм төньяк өлешен алдылар.

Выборг заливының көнбатыш ярында безнең частьләр уңышлы рәвештә алга баралар.

Суоярви—Сердоболь тимер юлының Лоймола станциясе районында пехота частьләренең бәрелешләре.

Безнең авиация дошманның сугыш объектларына актив хәрәкәтләр алып барды. Шул вакытта дошманның 5 самолеты бәреп төшерелде.

ИРАН БЕЛӘН ЯҢА СӘҮДӘ ДОГОВОРЫ ТУРЫНДА

СССР ның Тышкы Сәүдә Эшләре Халык Комиссариаты һәм Иранның сәүдә вәкиллеге арасында 1940 нчы елның 10 нчы мартында сөйләшүләрнең тәмам булуы нәтиҗәсендә ССР Союзының Иран белән сәүдә һәм диңгездә йөрү турындагы договоры парафировать ителде.

Совет ягыннан договор Тышкы Сәүдә Халык Комиссары иптәш А. И. Микоян һәм СССР ның Ирандагы вәкиле иптәш П. И. Алексеев тарафыннан парафировать ителде.

Иран тарафыннан договор Иранның Москвадагы гадәттән тыш һәм тулы хокуклы илчесе Сәед әфәнде һәм Иран хөкүмәте уполномоченные Саях әфәнде тарафыннан парафировать ителде.

Договорга якын көннәрдә Тиһран шәһәрендә кул куелачак. (ТАСС).

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI нче ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

ВКП(б) НЫҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ РЕВКОМИССИЯСЕНЕҢ ЭШЕ ТУРЫНДА

Иптәш А. Д. Арнаутов доклады

Иптәшләр!

Партия органнарына сайлаулар көненнән соң ике ел чамасы вакыт үтте. Бу чор эчендә илебез, коммунистлар партиясе һәм иптәш Сталин җитәкчелегендә гаять зур тарихи җиңүләргә иреште. Без бу җиңүләргә шуның өчен ирештек, чөнки коммунистлар партиясе партия турындагы Ленин—Сталин тәгълиматын һәр вакыт кулланып эш итте, аның оешу принципларын саклап кала алды.

Партия тарафыннан сайлап торган орган—ревизия комиссиясе үзенең эшендә оештыру принципларын нык сакларга, аларны ныгыту өчен барлык чаралар белән көрәшергә тиеш.

Партия уставы буенча, Өлкә ревизия, район һәм шәһәр ревизия комиссияләренең төп бурычларына партия оешмасының финанс хуҗалыгы системалы рәвештә тикшереп тору. Ләкин шуның белән бергә, 1939 нчы елның ноябрендә ВКП(б) Үзәк Комитетының оештыру бюросы карары буенча ревизия комиссияләре өстенә өлкә комитетлары, шәһәр комитетлары һәм район комитетлары аппаратында эшләрнең тиз һәм дөрес үтүен тикшерү эше дә йөкләнгән иде.

Үткән чор эчендә без ВКП(б) Өлкә Комитетының финанс хуҗалыгын документлар буенча өч ревизия һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты аппаратында эшләрнең тиз һәм дөрес үтүенә бер ревизия үткәрдек. Ревкомиссиянең өч пленумы һәм район ревкомиссияләре председательләренең бер киңәшмәсе үткәрелде. 4 район ревкомиссиясенең докладлары тыңланды.

Отчет чоры эчендә Татарстан партия оешмасы сафлары шактый үсте. 1938 нче елны ВКП(б) членнары 14.090, ВКП(б) кандидатлары 7.327 кеше булган булса, 1940 нчы елның 1 нче мартына инде ВКП(б) членнары 20.894 һәм кандидатлар 14.887 кешегә, ә барлыгы 35.781 кешегә җитте. Бу уңай белән, шулай ук бөтен партия эшенең гомуми күтәрелеше һәм илдә хезмәт хакының үсүе уңае белән, партия оешмасы кассасына кергән членлык взносларының гомуми сумасы шактый үсте. 1938 нче елны кергән членлык взнослары сумасы 1.563.047 сум булса, 1939 нчы елны ул 2.545.549 сумга җитте. Үсеш—160 процент.

Членлык взносларын түләүнең әһәмияте финанс ягында гына түгел. Ул партиябездә член булып торуның устав куйган шартларыннан берсе. Членлык взносларын җыюны дөрес куюның һәм партиянең бу бурычын үтәү буенча тәртипле рәвештә отчет бирүнең оештыру ягыннан әһәмияте әнә шуннан килеп чыга да. Большевиклар партиясенең һәм аның Үзәк Комитетының бу мәсьәләгә һәр вакыт әһәмият биреп килгәнлекләре һәм бирүләре әнә шуның белән аңлатыла да.

Отчет чоры эчендә членлык взносларын түләүнең торышын тикшерү, партия Өлкә Комитетының бу мәсьәләгә җидди әһәмият биргәнлеген күрсәтә. Партия взнослары буенча бурыч шактый кимеде. 1939 нчы елның 1 нче июленә ул 46.040 сум булган булса, 1940 нчы елның 1 нче январена 27.085 сумга кадәр төште, ягни 2 тапкыр диярлек кимеде. Саба, Алабуга һәм Балык Бистәсе кебек кайбер райкомнар бурычны тәмам бетерүгә ирештеләр.

Аннары иптәш Арнаутов членлык взнослары буенча бурычны бетерүдәге кимчелекләргә туктала. Январьда ул яңадан 40.628 сумга җиткән.

Сталин райкомы буенча 61 кешенең 3 айлыктан артыграк бурычы бар, шуның белән бергә, аларның күбесе партия белән һәр төрле элемтәләрен өзгәннәр, ләкин алар һаман да партия оешмасында дип саналалар. Бондюг райкомында, Зеленодольск шәһәр комитетында, Куйбышев райкомында һәм башка урыннарда да шундый ук фактлар бар.

Иптәш Арнаутов партия взносларын кабул итү буенча отчетларның вактында тапшырылмавына мисальләр китерә. Апас, Акташ һәм Норлат райкомнары декабрь отчетын берәр ай соңга калып тапшырганнар.

Аннары иптәш Арнаутов партия бюджетының расход өлешен, финанс контроленең, учетның һәм отчет бирүнең куелышын сөйләүгә күчә.

Татарстан партия оешмасының бюджеты 1937 нче елны 7 миллион 988 мең 600 сум, 1938 нче елны 13 миллион 426 мең 500 сум, 1939 нчы елны 19 миллион 979 мең 700 сум булды. Бу үсеш финанс хуҗалыгын алып баруны кискен төстә яхшыртуны һәм оператив эшләүне таләп итте.

Бюджетны үтәү буенча кайбер саннарны китереп үткәннән соң иптәш Арнаутов җитешсезлекләрне күрсәтеп үтә: кайбер чаралар буенча ВКП(б) Үзәк Комитеты җибәргән акчалар җитәрлек файдаланылмаган, җибәрелгән акчаларның аерым төрләре буенча артык расход тотылган, ВКП(б) Өлкә Комитетының финанс секторы райкомнарның эшенә системалы ревизия ясауны юлга салмаган.

Иптәш Арнаутов үзенең докладының икенче өлешенә күчә:

— Ревизия комиссиясе отчет чоры эчендә эшләрнең үтүенең тизлеген һәм дөреслеген тикшерде. 1939 нчы елның беренче январена партия документларын югалту турында 55 эш булган. Бер ел эчендә 388 эш кергән. Шулардан 403 эш каралган. 40 эш 1940 нчы елга күчерелгән. Партия җәзаларын алу турында 1939 нчы елның беренче январена 9 эш булган. Бер ел эчендә 205 эш кергән. Шулардан 189 эш каралган. 25 эш 1940 нчы елга күчерелгән.

Шулай итеп, каралмый калган эшләр саны кимемәгән. Билгеләнгән срокларны бозулар да бетерелмәгән.

1939 нчы елның икенче яртысында ВКП(б) Өлкә Комитетының чираттан тыш бюро утырышлары 5 көн саен булып торуга да карамастан, эшләрнең яртысы гына ВКП(б) Үзәк Комитеты билгеләгән срокларда каралган. Эшләрнең шактый өлеше кайбер райком секретарьларының гаепләре буенча тоткарланып килгән. Алар коммунистларның ВКП(б) Өлкә Комитетына баруларын тәэмин итмәгәннәр, шулай ук аларның эшләрен билгеләнгән таләпләр буенча рәсмиләштермәгәннәр.

1939 нчы елның 1 нче июленнән 1940 нчы елның 1 нче февраленә кадәр ВКП(б)сафларыннан чыгару турында ВКП(б) Өлкә Комитетында 291 эш каралган. 60 кеше партия сафларына кире кайтарылган, 200 кешенең чыгарылуы расланган, 30 эш ВКП(б) райкомнарына кайтарылган һәм бер эш архивка тапшырылган. Бу хәл ВКП(б) ның байтак кына райкомнарының эшнең ничек торганлыгын тирәнтен өйрәнмәүләрен күрсәтә һәм шуның нәтиҗәсендә ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы аларның карарларын юкка чыгарырга мәҗбүр булган. Тоткарлыкның төп сәбәпләре—тикшерүнең озакка сузылуыннан һәм партиядән чыгарылган кайбер кешеләрнең чакыру буенча ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросына килмәүләреннән гыйбарәт.

ВКП(б) сафларыннан чыгарылу һәм партия җәзалары бирелү турындагы апелляцияләрнең хәрәкәте турында берничә сүз. 1939 нчы елны ВКП(б) Өлкә Комитетына 510 апелляция кергән. Шулардан 403 апелляция каралган, 107 апелляция тикшерелми калган. Шулардан 23 е ВКП(б) Үзәк Комитеты янындагы Партия Контроле Комиссиясенең Татарстан Партколлегиясеннән кергән апелляцияләр. Бу хәл чакырылган кешеләрнең ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросына килүләрен начар тәэмин итүдән һәм ВКП(б) членнарының һәм кандидатларының язмышларына ВКП(б) Өлкә Комитетының оештыру-инструкторлык бүлегендәге кайбер работникларның игтибарсыз карауларыннан килеп чыккан.

Аннары иптәш Арнаутов учёт, отчет бирү, партия документларын саклау турында сөйләп, Татарстанның бөтен партия оешмасында бу эшнең куелышы шактый яхшырганлыкны әйтеп үтә. Ләкин кайбер районнарда, бигрәк тә Олы Тархан, Юдино, Кызыл Йолдыз районнарында учет эше, партия документларын рәсмиләштерү һәм саклау канәгатьләнерлек хәлдә түгел. Партиянең бу оешмалары Үзәк Комитетның 1935 нче елгы декабрь пленумы таләпләрен тулысынча үтәмиләр. Пленум исә партия аппаратының җаваплы работникларын партия документларының саклануын тикшерү белән турыдан-туры шөгыльләнергә мәҗбүр иткән иде.

Протокол хуҗалыгының торышы турында сөйләгәндә иптәш Арнаутов отчет чоры эчендә бу эштә ВКП(б) Өлкә Комитетының үз аппаратында да, шулай ук ВКП(б) райкомнарында да шактый яхшыру барлыкны әйтеп үтә. ВКП(б) Өлкә Комитетында ревизия комиссиясе бер нинди дә әһәмиятле кимчелекләр тапмады. Протоколларны һәм партиянең башка документларын саклау тәмам канәгатьләнерлек куелган.

Ләкин күп кенә райкомнар (Әгерҗе, Беренче Май, Ютазы, Дөбъяз һәм башка райкомнар) протоколларны чиктән тыш канәгатьләнмәслек, саксыз һәм җавапсыз төзиләр. ВКП(б) ның Тельман, Биектау, Кызыл Йолдыз, Кайбыч, Питрәч, Лаеш райкомнары һәм башкалар ВКП(б) Өлкә Комитетына протоколларны вактында тапшырмыйлар. Тоткарлык еш кына 3 айга кадәр һәм артыгракка да җитә. Мәсәлән, ВКП(б) ның Лаеш райкомы 1938 нче елның октябрендә булган пленумының протоколын ВКП(б) Өлкә Комитетына 1939 нчы елның 17 нче апрелендә генә җибәргән.

Бу эштә, бер яктан, ВКП(б) Өлкә Комитетының информация секторы гаепле. Ул аерым ялгышларны һәм җитешсезлекләрне вактында ачмый. Шулай ук оештыру-инструкторлык бүлеге һәм махсус бүлекләр дә гаепле. Алар протокол хуҗалыгын ВКП(б) Үзәк Комитеты таләпләренә туры китереп рәсмиләштерүдә ВКП(б) райкомнары работникларына бик аз булышлык иткәннәр.

Докладының ахрында иптәш Арнаутов болай ди:

— Мин әйтергә тиешмен, баштарак ревкомиссия дә канәгатьләнерлек эшләмәде, тик 1939 нчы елның уртасында гына ВКП(б) Үзәк Комитетына чакырылганнан соң гына без үзебезнең эшебезне яхшырттык. Бу зур, җаваплы һәм мактаулы эштә ревкомиссия членнарыннан кайберләренең актив катнашмаганлыкларын әйтергә кирәк. ВКП(б) Өлкә Комитеты бүлекләрендә дә күп кенә җитешсезлекләр бар әле. Алар кешеләргә игтибар белән̣рәк карарга, ВКП(б) Үзәк Комитеты заданиеләренең үтәлүен җентекләп тикшерергә тиешләр. Без, партиябезне иптәш Ленин өйрәткәнчә, иптәш Сталин өйрәтә торганча, большевикларча эшли алабыз һәм эшләргә тиешбез.

БУЛДЫРЬ НЕФТЬ ПРОМЫСЛОЛАРЫНДА

НЕФТЬ ФОНТАНЫ АТУ АЛДЫННАН

БУЛДЫРЬ. (Телефон буенча). 1 нче номерлы скважинада эш кайный. Кечкенә коллективның бөтен игтибары нефть аткан катлауга тизрәк барып җитүгә юнәлдерелгән. Нефть фонтаны түземсезлек белән көтелә.

— Нефть бар! Ул инде еракта түгел, берничә метр тирәнлектә генә ятә! Бу фикер һәрбер эшченең, һәрбер геологның күңелендә яшәп тора. Чөнки бораулау нәтиҗәсендә чыккан таш токымнарын җентекләп тикшерү моны ачык һәм ышанычлы раслый.

Бораулау эше зур күтәренкелек белән бара. 11 нче мартта бурильщик иптәш Шуппе 992 метр тирәнлектә керн (тау токымы) алды. Аннан нефть исләре аңкып тора. Разведка работниклары аны җентекләп тикшергәч, фәнни яктан өйрәнәләр. Өлкән геолог Иванисьян, буровой начальнигы Г. Чубов, мастер З. Хәмидуллин, бораулаучылар А. Дмитриев, Д. Дорофеев иптәшләр беренче нефтьне алу өчен аерым зур тырышлык белән көрәшәләр.

Скважина коллективы нинди кенә түземсезлек белән нефть көтсә дә, бораулау эшен зур сак белән дәвам итә. Бу токымны бик сак, бораулау приборлары бик тиз туза. Ләкин ничек кенә булмасын, максатка ирешүгә күп калмады—„кара алтын" еракта түгел, газлы балчыклы сыекча алынды да ул үзе дә тиз ага.

Берничә көн түгел, һәм Татарстан хезмәт ияләре түземсезлек белән көткән „кара алтын"— нефть фонтаны бәреп чыгар. Моңа инде шик юк!

К. Исламов.

ВКП(б) нын ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI нче ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ҺӘМ РЕВИЗИЯ КОМИССИЯСЕНЕҢ ОТЧЕТЛАРЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУЛАР

Яңа шәһәрнең яңа таләпләре

ВКП(б) ның Зеленодольски шәһәр комитеты секретаре иптәш Суганов речennән

Иптәшләр! Отчет чорында партия оешмаларының авторитетлары һәм коммунистларның авангардлык рольләре нык үсте һәм бу хәл үзенең яхшы нәтиҗәләрен бирде. Партоешмалар үз эшләрен ВКП(б) нын XVIII нче съезды карарлары нигезендә яңа баштан кордылар, масса белән элемтәне көчәйттеләр. Партияле һәм партиясез большевикларның мораль һәм политик бердәмлеген тагын да ныгытуга ирештеләр.

Шулай да, бу казанышлар безгә тынычлану хокукын бирмиләр. Татарстан партия оешмасының барлык звенолары да яхшы эшләделәр дип әйтеп булмый әле. Мисаль өчен партиянең Зеленодольски оешмасын алыйк. Иптәш Алемасов докладында промышленность предприятиеләренең эшенә карата булган тәнкыйть безнең оешмага да бик нык кагыла. Безнең шәһәр предприятиеләре үзләренең планнарын 1938 нче елда да, шулай ук 1939 нчы елда да үтәп житкермәделәр. Артта калучылык быел да дәвам итә. Завод-фабрика житәкчеләре бу хурлыклы хәлгә карата килешүчәнлек күрсәтәләр.

Партиянең Зеленодольски шәһәр оешмасы отчет чорында шактый гына үскән. Ләкин аның сыйфаты канәгатьләнерлек түгел. Бу эш әле үз агымы белән генә бара. Алдынгы эшчеләр, хатын-кызлар исәбенә булган үсешнең йомшак булуы әнә шул турыда сөйли. ВКП(б) Өлкә Комитетының оештыру-инструкторлык бүлеге вәкилләре шәһәр оешмасында еш кына булуларына да карамастан, эшнең бу тармагына житәрлек игтибар итмәгәннәр.

Зеленодольски шәһәре—ул яңа һәм үсүче шәһәр. Ләкин менә республика оешмалары шәһәрне төзекләндерү мәсьәләләрендә безгә тиешле практик ярдәмне күрсәтмиләр. Юллар, транспорт мәсьәләсен алыйк. Зеленодольски Казан шәһәреннән 45 километр гына ераклыкта тора. Шуңа карамастан, элемтә мәсьәләсе чиктән тыш начар. Ике зур шәһәр арасындагы юлны төзекләндерү эше тиз арада хәл ителергә тиеш.

Паратский разъезды белән дә аяныч хәл хөкем сөрә. Бу разъезд йөзләрчә, меңнәрчә пассажирларга хезмәт күрсәтсә дә, аны тәртипкә китерү турында һич кем кайгыртмый. Тимер юл житәкчеләре үз хуҗалыкларына җансыз карыйлар. Юк исә вокзал төзү һәм тимер юлчыларның көнкүреш-тормыш шартларын яхшырту өчен практик чаралар күрергә мөмкин булыр иде.

Кыскасы, өлкә оешмалары, шул исәптән ВКП(б) нын Өлкә Комитеты да, яңа төзелә торган Зеленодольски шәһәренә игтибарны көчәйтергә, алда торган эшләрне башкаруда практик ярдәм күрсәтергә тиешләр.

Мәктәпләргә житәкчелекне көчәйтергә

ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе урынбасары иптәш Афанасьева речennән

Мин практик эштәге кайбер кимчелекләргә тукталып үтәргә уйлыйм. Минемчә, ВКП(б) нын Өлкә һәм район комитетлары тарафыннан да, халык мәгарифе органнары тарафыннан да, Наркомпрос һәм аның наркомы иптәш Контюков тарафыннан да мәктәпләрдәге укыту-тәрбия эшләренә тиешле игтибар бирелмәде. Өлгереш һәм балаларны коммунистик рухта тәрбияләү буенча аерым мәктәпләрнең начар эшләүләре моны тулысынча раслыйлар.

Казан шәһәрендәге 85 нче номерлы мәктәп уку елының беренче чирегең бары тик 50 процент өлгереш белән тәмам итте. Мәктәптә ныклы режим һәм дәресләрне дөрес оештыру булдырылмаган. Дәрескә кичегеп килү, мәктәп балалары арасында хулиганлык, тәрәзә вату, тәмәке тар-

ту һәм башка шундый фактлар еш кына кабатланалар.

Наркомпрос бу хәлне белеп, мәктәпнең эшен тикшергән иде. Тикшерү комиссиясенең йомгаклары Наркомпроста 5 нче февральдән бирле яталар, ләкин мәктәпнең эшен яхшырту чаралары күрелми.

Укытучылар арасында политик-тәрбия эшләренең торышы тиешле югарылыкта түгел. ВКП(б) нын Өлкә һәм район комитетлары, халык мәгарифе органнары мәктәпкә житәкчелекне, балаларны тәрбияләү эшләрен тамырыннан яхшыртырга тиешләр.

Укый-яза белмәүчелекне бетерү һәм аз укый-яза белүчеләрне укыту эшенә партия һәм хөкүмәтебез барлык шартларны тудырдылар. Безнең кайбер районнарыбыз тулы грамоталы районнар булу алдында торалар. Ләкин күпчелек районнарда бу мәсьәлә белән тиешенчә шөгыльләнмиләр әле. Зурларны укыту өлкәсендә кискен борылыш ясарга тиеш.

Орденлы Татарстан 25 нче июньдә үзенең егерме еллыгын бәйрәм итәчәк. Бу датаны социалистик төзелешнең барлык тармакларында яңа җиңүләр белән каршы алу өчен көрәшкә хезмәт ияләрен тагын да ныграк тупларга тиешбез.

Кадрларыбызның теоретик белемнәрен күтәрү өчен

В. И. Ленин исемендәге завод пропагандисты иптәш Дельвин речennән

Партия пропагандасын оештыруда безнең уңышларыбыз шактый зур. Ләкин алар һич тә житәрлек түгел әле.

Безнең житәкче кадрларыбызның күпчелеге үзенең белемен күтәрү өстендә аз эшли. Партиянең күп кенә башлангыч оешмалары теоретик белемне күтәрү өчен системалы рәвештә үзлегеннән укырга кирәклекне бу иптәшләргә аңлату һәм аларга бу эштә көндәлек булышлык оештыру буенча житәрлек эшләмәделәр. Кайбер башлангыч партоешма житәкчеләре үзләре дә теоретик белемнәрен күтәрү белән җидди шөгыльләнмиләр. Башлангыч оешмаларның күпчелегендә партия пропагандасы буенча планлы эш алып барылмый. Нәтиҗәдә алар партия пропагандасы мәсьәләләре белән очраклы гына шөгыльләнәләр, бу эш үз агымына куела.



Партия тарихын түгәрәкләрдә өйрәнүне оештыру эше дә канәгатьләнерлек тормый. Түгәрәкләр һаман да искечә эшлиләр. Укучылар китап өстендә үзлекләреннән эшләүгә өйрәтелми. Алар дәресләргә хәзерләнми киләләр, күп хәлләрдә түгәрәккә йөрүдән бөтенләй туктыйлар. Мисаль өчен безнең заводтагы берничә түгәрәкне алырга мөмкин. Пропагандист иптәш Аронов түгәрәгендә 26 кеше укырга тиеш иде. Беренче дәрескә—19 кеше, икенчесенә—13, өченчесенә—9, дүртенчесенә һәм бишенчесенә — 6 кына кеше килде. Жиденче дәрескә исә бер кеше дә килмәде һәм шуның соң түгәрәк бөтенләй онтылды. Икенче бер түгәрәктә „Кыска курс" ның беренче бүлеге буенча 8 занятие үткәрергә туры килгән. Чөнки монда һәрбер занятиегә яңа кешеләр килеп торганнар. Пропагандист иптәш Гайсинга да, шул ук сәбәп буенча, партия тарихын өйрәнүнең әһәмияте турында 3 занятие үткәрергә туры килгән.

ВКП(б) нын Өлкә һәм шәһәр комитетларының пропаганда һәм агитация бүлекләре урыннарда житәрлек оператив эш алып бармыйлар, башлангыч оешмаларда партия пропагандасының торышы белән якыннан танышмыйлар. Үзебезнең завод оешмасына карата мин моны ачык әйтә алам. Өлкә Комитетыннан да, шулай ук Шәһәр Комитетыннан да бу мәсьәлә буенча безгә килүче булмады. Бу бүлекләрнең партоешма белән булган элемтәләре аерым мәсьәләләр турында белешмәләр алудан гына гыйбарәт булды. Алар оешмага бу эштә җанлы, конкрет житәкчелек һәм булышлык күрсәтмәделәр.

Безнең бурыч — барлык партоешмаларда да партия пропагандасы эшен кискен рәвештә яхшыртудан гыйбарәт. Моның өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар.

Дәүләт планы тулысынча үтәлергә тиеш

ТАССР ның җиңел промышленность наркомы иптәш Измайлова речennән

Партиябезнең тарихи XVIII нче съезды безнең алга төп экономик бурыч итеп, Европаның иң алга киткән капиталистик илләрен һәм Америка Кушма Штатларын экономик яктан да якындагы 10—15 ел эчендә куып җитү һәм узып китү бурычын куйды.

Тарихи съезд тарафыннан куелган бу бурычларны тормышка ашыру өлкәсендә Татарстан партия оешмасы шактый эшләр башкарды. Иптәш Алемасов үзенең докладында бу турыда киң рәвештә тукталды.

Мин, ТАССР ның җиңел промышленность наркоматы эше турында сөйләргә телим. Хезмәт җитештерүчәнлеген без 1939 нчы елда, 1937 нче ел белән чагыштырганда, 40,3 процентка, продукция эшләп чыгаруны 17,2 процентка үстердек. Стахановчылар саны

наркомат предприятиеләрендәге барлык эшчеләргә карата 34 проценттан 53 процентка җитте. Гүзәл стахановчылык хәрәкәте йөзләрчә атаклы кешеләрне тудырды һәм аларны тәрбияләп үстерде. Монда партия оешмаларының роле гаять дәрәҗәдә зур булды.

Ләкин, гомумән алганда, 1939 нчы елда без канәгатьләнерлек эшләмәдек. Еллык планны 97,8 процентка гына үтәп, илгә 3.125 мең сумлык продукция биреп җиткермәдек. Сыйфат күрсәткечләре түбән булу аркасында, 1.899 мең сумлык зарар күрдек. Казандагы һәм Кукмарадагы киез итек фабрикалары аеруча начар эшләделәр. Наркомат системасында хезмәт хакы фондын дөрес файдаланмау фактлары да булды. Мәсәлән, Ленин исемендәге күн заводы хезмәт хакы фондын планга караганда, 386 мең сум артык тоткан. Совет законнарын бозучыларга каршы көрәш йомшак оештырылган. Без завод, фабрика директорларыннан совет законнарының төгәл үтәлүен җитәрлек таләп иткәнебез юк.

Промышленность предприятиеләренә Татарстан Совнаркомының начар җитәкчелек итүен аеруча әйтергә кирәк. Совнарком эшлекле һәм сәләтле работниклар белән тупланмаган.

Госплан соңгы елларда үзенең эшен бераз яхшыртса да, бүгенге көн таләпләреннән артта кала әле. Промышленность предприятиеләренең эшен планлаштыру мәсьәләсе белән иптәш Быстров бик аз кызыксына. Наркоматлар тарафыннан бирелгән таблицаларга үз вакытында тиешле анализ ясалмый. 1939 нчы ел өчен төгәл планны без ел ахрында, 27 нче декабрьдә генә алдык. Елның-ел буена башлангыч план буенча гына эшләргә туры килде. Бу хәл быел да кабатлана. 1940 нчы елның январь аенда башлангыч план алынды. Бу план январь, февраль айларында 106,2 процент итеп үтәлде. Шуңа карамастан, моннан 3 көн генә элек главка безгә „яңа" план төшерде. Бу планда продукция эшләп чыгару башлангыч планга караганда, 600 мең сумга киметелгән. Менә, главка җитәкчеләре фактик үтәлгән планны киметү кебек әдәм көлкесенә кадәр барып җитәләр.

Мондый „планлаштыруның" кемгә кирәге бар соң? Бу мәсьәлә белән Совнарком һәм Госплан җитәкчеләре җиддиерәк шөгыльләнергә тиешләр. Билгеләнгән планны тулы һәм арттырып үтәү өчен безнең бөтен мөмкинлекләребез бар.

Ерак районнарга игтибар җитәрлек түгел

ВКП(б) ның Азнакай райкомы секретаре иптәш Хәмидуллин речennән

Отчет чоры эчендә ВКП(б) нын Азнакай район оешмасы да шактый ныгыды. Отчет чорында районда партиягә членлыкка һәм кандидатлыкка барлыгы 399 кеше кабул ителде. Барлыгы 156 кешене партия һәм совет оешмаларына җитәкче эшләргә күтәрдек. Шуларның 36 сы хатын-кызлар, 88 е коммунистлар.

Кадрларны өйрәнүгә, сайлап



алуга һәм бигрәк тә аларга эштә практик булышлык күрсәтүгә җидди игтибар итү безгә бик яхшы нәтиҗәләр бирде. Мисаль өчен мин „Яңа Көч" колхозын алам. Бу колхоз авыл хуҗалыгы эшләрен үтәү буенча берничә ел буена районда иң артта баручы колхозларның берсе иде. Партиянең район комитеты колхозның артта калу сәбәпләрен ныклап өйрәнде һәм аңар конкрет җитәкчелекне тәэмин итте. Нәтиҗәдә, бу колхоз бик тиз арада районның алдынгы колхозларыннан берсенә әйләнде.

Өлкә оешмалары тарафыннан районнарга җитәкчелек турында берничә сүз. Турыдан-туры әйтергә кирәк: ерак районнарга, аерым алганда безнең Азнакай районына, Татнаркомземнең да һәм шулай ук ВКП (б) Өлкә Комитеты авыл хуҗалыгы бүлегенең дә җитәкчелеге һич тә җитәрлек түгел.

Азнакай районына тагын бер МТС кирәк. Ләкин яңа МТС лар оештыруны планлаштырганда Татнаркомзем Азнакайны читтә калдырды. Тракторларга ремонт эшендә һәм, гомумән, безнең районыбызда язгы чәчүгә хәзерлек эшендә Татнаркомзем бик йомшак катнаша, эшне плансыз алып бара. Безнең МТС тракторларга ремонт ясауда артта бара. Моңар, барыннан да элек, Татнаркомзем гаепле. Чөнки безнең МТС ка җибәрергә тиешле токарьный станокны Татнаркомзем һичбер кирәксезгә Бөгелмәгә җибәргән. Нәтиҗәдә, безнең МТС төзәтү өчен үзенең моторларын Бөгелмәгә—65 километр ераклыкка ташып йөрергә мәҗбүр була. Татнаркомземның җитәкче работниклары урыннарга барып турыдан-туры булышлык күрсәтәсе урында, күбрәк районнардан работникларны төркем-төркем итеп Казанга чакырып китерәләр. Болай эшләү дөрес түгел. Болай эшләү—дәүләт средстволарын туздыру.

ВКП (б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге дә районнар белән нык бәйләнеш тотмый. Азнакай районында бу бүлектән бер генә работникның да булмавы моны ачык күрсәтеп тора. Авыл хуҗалыгы бүлеге бу практиканы, кабинеттан торып җитәкчелек итүне ташларга, районнарга конкрет рәвештә җитәкчелек итүгә күчәргә тиеш.

Массовый оборона эшенә игтибарны көчәйтик

Тәтеш райвоенкомы иптәш Хәбибуллин речennән

ВКП(б) ның XVIII нче съезды массовый оборона эшенә партия җитәкчелеген яхшырту бурычын куйды. Партиянең Тәтеш район оешмасы бу күрсәтмәне ничек үтәде соң?

1939 нчы елда партиянең район оешмасы запастагы рядовойлардан һәм кече начсоставтан күп кенә иптәшләрне РККА ның командный постларында эшләргә хәзерләү эшенә булышты. Чираттагы призыв аеруча нык оешканлык белән үтте. Кызыл Армия сафларына китүчеләр барсы да грамоталы иптәшләр, аларның 89 проценты оборона значкистлары.



Районда массовый оборона эше сизелерлек рәвештә яхшырды. 1939 нчы елның 1 нче январена безнең районда барлыгы 62 Осоавиахим оешмасы булса, хәзерге көндә аларның саны 80 гә җитте. Бу оешмаларда 3.086 кеше член булып тора. Үсеш, 1938 нче елдагыга чагыштырганда, 63 процент.

Ләкин, иптәшләр, безнең районда, гомумән алганда, массовый оборона эше партиянең XVIII нче съезды тарафыннан куелган таләпләргә тулысынча җавап бирерлек дип әйтеп булмый әле. Осоавиахим һәм РОКК эшен тиешле югарылыкка күтәрәсе, бу оешмаларга булышлык күрсәтүне күп яхшыртасы бар.

Партия оешмалары оборона эшенә конкрет рәвештә җитәкчелек итәргә тиешләр.

ВКП(б) УСТАВЫ ТАЛӘПЛӘРЕН ТУЛЫ ҮТӘРГӘ

ВКП(б) Өлкә Комитетының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире иптәш Жуков речennән

Безнең конференциядә партиянең эчке эшләре мәсьәләсе тиешле урынны алды. Бу нәрсә бездә партиянең эчке эшләре мәсьәләсенә, партия-масса һәм оештыру эшләренә җаваплылык сизүнең нык күтәрелүен күрсәтә.

Өлкә Комитетының оештыру-инструкторлык бүлеге тарафыннан үткәрелгән чаралар, барыннан да элек, яңа эшкә килгән кадрларны өйрәтүгә юнәлтелгән иде. Райкомнарның оештыру-инструкторлык бүлекләре мөдирләре һәм инструкторлары өчен семинарлар үткәрелде.

Оештыру-инструкторлык бүлегенә карата булган тәнкыйтьләр дөрес һәм урынлы. Бездә кимчелекләр күп әле. Безнең эчке-оештыру эшләребездә бигрәк тә артта калган тармак бар. Ул—партиядән чыгару һәм партиягә кире кайтару мәсьәләсе. Дөрес, коммунистларның язмышын хәл итүгә җаваплылык сизү көчәйде. Ләкин әле бу эштә җидди һәм зур кимчелекләр бар. Партиябезнең XVIII нче съезды, коммунистларны

партиядән чыгару яки партиягә кире кайтару мәсьәләсен хәл иткәндә нык саклылык, эшне җентекләп тикшерү, иптәшләрчә мөнәсәбәт кирәклеген аеруча күрсәткән иде. Ләкин барлык партоешмалар тарафыннан да бу күрсәтмәләр тулы үтәлә дип булмый. Безнең партоешмада партиядән нигезсез чыгару һәм җәза бирү фактлары аз түгел. Коммунистка нигезсез гаепләр ташлаулар бар әле. Бу—төп җитешсезлекләрнең берсе. Менә берничә фактны китерәм. Арча райкомы үткән елның декабрь ахрында берәүгә „җаваплы эштән баш тартканлыгы өчен" дип шелтә биргән. Бу кешенең эше белән ныклап танышкач, аңа суд тарафыннан җаваплы эш бирү тыелганлыгы беленде. Менә монда инде райкомның кадрларны сайлап алуга һәм партия җәзасы бирүгә ничек ялгыш караганлыгы күзгедәге кебек ачык күренеп тора.

Коммунистларның язмышын хәл иткәндә зарарлы ашыгучанлык фактлары бар. Алексеевский райкомы 1939 нчы елны берәүне партиядән чыгара һәм суд җаваплылыгына тартырга тәкъдим итә. Суд озак вакыт тикшергәннән соң аны җавапка тартырлык бернинди җинаять тә тапмады. Өлкә Комитет райкомның бу кеше турындагы карарын, дөрес булмаганлыктан, расламады.

Аның соңында, аерым коммунистларны, аларга теге яки бу гаепләре буенча ВКП(б) уставы нигезендә тиешле җәза чараларын кулланмыйча, гаепләрнең сәбәпләренә анализ ясамыйча, партиядән чыгарулар бар.

Бездә коммунистларны тәрбияләү буенча җитәрлек эш алып барылмый. Кай вакытта членның яки кандидатның кимчелек якларын гына күрү, аңа схематик карау, кешенең яхшы якларын күрә белмәү фактлары очрый.

Менә бу фактлар әле безнең кайбер җитәкче иптәшләрнең ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларыннан кирәкле нәтиҗәне ясап җиткермәүләрен күрсәтәләр. Партия оешмалары партиянең эчке оештыру эшләрен тагын да ныгыту өчен көрәшергә, ВКП(б) уставы таләпләрен тулы үтәүне тәэмин итәргә тиешләр.

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI нче ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ һӘМ РЕВИЗИЯ КОМИССИЯСЕНЕҢ ОТЧЕТЛАРЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУЛАР

Яш кадрлар турында

ВКП(б) ның Яңа Чишмә райкомы секретаре иптәш Алешков речennән

Партия кадрларын үстерүдә, аларны тәрбия итүдә, безнең совхозларыбызны һәм колхозларыбызны ныгытуда, партия мәгарифен яхшыртуда һәм башка бик күп мәсьәләләрдә партиянең Татарстан оешмасы отчет чоры эчендә зур уңышларга ирешкән. Без моны иптәш Алемасов докладыннан ачык күрдек.

Партиянең Яңа Чишмә район оешмасы эшендә дә яхшыру һич шиксез бар. Без партиянең XVIII нче съездыннан соң үзебезнең сафларыбызны иң яхшы иптәшләр белән шактый тулыландырдык. Партия оешмасы үсү белән бергә безнең районыбызда җитәкче яш кадрлар сафы да үсте. Мәсәлән, отчет чорында партиягә кабул ителгән иптәшләр арасыннан без 52 иптәшне җитәкче эшләргә күтәрдек.

Ләкин партиянең район оешмасы эшендә зур кимчелекләр дә бар. Партиянең район комитеты партия сафларын төп профессияләрдәге эшчеләр, тракторчылар һәм комбайнчылар хисабына үстерү бурычын үти алмады. Отчет чоры эчендә партиягә кабул ителгәннәрнең бары тик 9 процентын гына тракторчыларның, комбайнчыларның һәм башка шундый төп профессия кешеләренең тәшкил итүе моны ачык күрсәтеп тора.

Иген уңышын күтәрү буенча партиянең XVIII нче съезды карарын үтәмәвебез безнең иң зур кимчелегебез булып тора. Иген уңышын күтәрү буенча партия тарафыннан куелган бурычны безнең районыбыз үткән елны бары 35 процентка үтәде. Моның төп сәбәбе, барыннан да элек, иген уңышын күтәрү мәсьәләсе белән безнең бик начар шөгыйльләнүебездә, агротехника чаралары планын өзеп килүебездә һәм төп чараларны да (туңга сөрү һәм башкалар) җиренә җиткереп үтәмәвебездә.

Бу уңай белән ВКП(б) Өлкә Комитеты җитәкчелеге турында да әйтеп китәргә кирәк. Дөрес, без Өлкә Комитетыннан директив күрсәтмәләрне күп алдык. Бу, әлбәттә, начар түгел. Өлкә Комитеты тарафыннан җыелган төрле киңәшмәләрдә дә без булдык. Бу да яхшы. Ләкин безнең өчен, яш кадрлар өчен, тәҗрибәләре җитәрлек булмаган кадрлар өчен, мондый булышлык кына һич тә җитәрлек түгел.

Яш кадрлар турында ныклы кайгыртучанлык күрсәтүнең, аларга эштә конкрет булышлык күрсәтүнең җитәрлек булмавын Өлкә Комитеты бүлекләре эшендә төп кимчелек дип исәпләргә кирәк. ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге партиянең авыл райкомнары өчен булышлык күрсәтелә торган үзәк булырга тиеш иде. Ләкин бу бүлек безгә начар булыша әле. Мин Яңа Чишмә районында ел ярымнан бирле эшлим. Шул чор эчендә ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлегеннән дә һәм шулай ук Татнаркомземнан да Яңа Чишмә районына килеп караган һәм чынбарлык белән танышып, урындагы работникларга конкрет булышлык күрсәткән бер генә работникны да күрмәдем. Бу нәрсә дигән сүз? Бу, масса белән элемтәдә булу һәм ул элемтәне ныгыту турында иптәш Сталин күрсәтмәсен оныту дигән сүз. Яш кадрлар турында кайгыртучанлык күрсәтүне һәм аларга эштә практик булышлык күрсәтүне тамырыннан яхшыртырга кирәк.

Партия хуҗалыгында большевистик тәртипне тагын да ныгытыйк

Кайбыч райкомы секретаре иптәш Акчурин речennән

Мин, партия хуҗалыгы мәсьәләсенә тукталырга уйлыйм. Ревкомиссия докладына һәм чыгып сөйләүләргә караганда, бездә партия хуҗалыгын алып бару эше отлично тора дип уйларга мөмкин. Дөрес, партдокументларны тикшерү һәм алмаштыру эше үткәрелгәннән соң партия хуҗалыгында большевистик тәртип урнаштырылды. Ләкин кайбер партоешмаларда партия хуҗалыгы алып баруга тиешле игтибар ителми әле. Моны раслау өчен берничә мисаль китерергә мөмкин. Ревкомиссия докладында өлкә комитетның барлык секторларында да бик шәп тәртип кертелгәнлеге турында әйтелде. Мин, алай ук дип әйтмәс идем. Өлкә Комитетның бюро карарлары язылган протоколлар райкомнарга җибәрелә һәм алар бер айдан да соңга калдырылмыйча кире кайтарылырга тиеш. Ә кайбер райкомнар тарафыннан бу нәрсә эшләнми. Мәсәлән, Кайбыч партоешмасы 1939 нчы елның сентябрь аеннан бирле Өлкә Комитет бюросының бер протоколын да кире кайтармаган.



Өлкә Комитет бүлекләренең инструкторлары адресына бу турыда ныклап әйтергә кирәк. Алар партоешмаларда партия хуҗалыгын алып бару эшенә әһәмият бирмиләр. Өлкә Комитеттан килгән инструкторларның партоешмаларда партия хуҗалыгы торышы белән кызыксынулары турында бер фактны да хәтерләмим. Контроль булмау нәтиҗәсендә, кайбер партоешмаларда партия хуҗалыгын алып баруга һәм аны саклауга җавапсыз караулар бар.

Урыннардагы оешмаларга конкрет булышлык итәргә

Минзәлә райкомы секретаре иптәш Хәкимҗанов речennән

Партия оешмаларында булып үткән отчет-сайлау җыелышлары һәм район партконференцияләре ирешелгән уңышларга тирән анализ ясау, булган кимчелекләрне большевикларча тәнкыйтьләү астында үттеләр. Алар безнең практик эшебездә җибәрелгән ялгышлыкларны һәм кимчелекләребезне төзәтү өчен күп кенә эшлекле тәкдимнәр керттеләр.

1939 нчы елда авыл хуҗалыгы эшләре начар күрсәткечләр белән тәгәлләнде. Моның төп сәбәбе: партоешмаларның масса-политик эшне йомшартуларында. Партия райкомнары, Татнаркомзем һәм ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге стахановчыларның һәм колхозларның аерым уңышлары белән мавыгып, югары [illegible] Без бу кимчелекләрдән тиешле нәтиҗә ясарга һәм партиябезнең XVIII нче съезды таләпләрен тулы үтәүне тәэмин итәргә тиешбез.

Чувашстан АССР һәм Мордовия белән Татарстан АССР арасында социалистик ярыш договоры төзелгән иде. Ләкин, конференциядә китерелгән фактлар, бу договорны үтәүдә Татарстан Наркомземының чиктән тыш начар эшләвен күрсәтәләр.

Татарстан Совнаркомының эше һәм җитәкчелеге турында берничә сүз. Җирле Советларга яңа кадрлар сайланды, аларга конкрет җитәкчелек кирәк. Ләкин Совнарком Советларның практик эшләренә кирәгенчә җитәкчелек итми. Мәсәлән, январь аенда Совнарком райсовет башкарма комитетларының председательләре белән киңәшмә уздырды. Анда Совнарком председателе берничә сәгать речь сөйләде, аннан соң аның урынбасарлары һәм наркомнар чыгып сөйләделәр. Ә җирле Советлардан бер генә доклад та куелмаган.

Партия пропагандасы өлкәсендә бездә күп нәрсә эшләнде, шуның белән бергә алда тагын да бик күп эшлисе бар әле. ВКП(б) Өлкә Комитетының пропаганда һәм агитация бүлегенең кимчелеге итеп шуны әйтергә кирәк: аның лекторлары районнарда бик сирәк булалар. Безнең районда, мәсәлән, 1939 нчы елда лекторлар бары тик өч тапкыр булдылар. Анда да, алдан хәбәр итмәү нәтиҗәсендә, ашыгычлык килеп чыга, эшне дөрес оештыру мөмкинлеге булмый. Лекторлар моны киләчәктә искә алырлар.

Татнаркомзем органы „Колхоз бригадиры" журналы турында шуны әйтәсе килә: журналның колхоз җитәкчеләре өчен файдасы зур, ләкин аның үз вакытында килүен тәэмин итәргә кирәк.

Партия сафлары иң яхшылар хисабына үсә

Тымытык райкомының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире иптәш Миңнегалиев речennән

Отчет чоры эчендә, бигрәк тә партиянең XVIII нче съездыннан соң Тымытык партоешмасы ике тапкырга диярлек үсте. Башлангыч партоешмалар саны 8 дән 23 кә җитте. Партия членнарының саны 1938 нче елда 66 дан хәзер 153 кә, кандидатлар—54 тән 117 гә җитте.

Партия сафлары иң яхшылар хисабына үсә. Партиягә яңа кабул ителгәннәр арасында Дәүләтшин, Кәримев, Вахитов иптәшләрне мисалга алырга була. Комбайнер иптәш Дәүләтшин узган елда 995 гектар мәйданнан урып-җыеп ирешле. Авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнашып Зур Алтын медаль белән бүләкләнде. Ул үзенең политик белемен күтәрү белән дә нык шөгыльләнә, җәмгать эшләрендә актив катнаша. Иптәш Дәүләтшин—район советы депутаты.

Эштә яхшы үрнәкләр күрсәткәннәре өчен трактор бригадиры иптәш Кәримев Зур Алтын медаль белән, иптәш Вахитов „Комбайн мастеры" значогы белән бүләкләнделәр. Партиягә яңа алынганнар арасында шундый алдынгыларны берничәләп санарга мөмкин.

Партиянең XVIII нче съезды карарлары нигезендә партия органнары аппаратын яңача оештырганнан соң партиянең эчке эшләре, партия хуҗалыгы һәм аерума тикшерү мәсьәләләре яхшырды.

Шуның белән бергә безнең эшебездә җидди кимчелекләр дә бар әле. Безнең район партоешмасында узган елны партия кандидатлыгына һәм членлыкка кабул ителгәннәрдән 21,3 проценты гына колхоз производствосында эшләүчеләр. Күп кенә колхозларда әле партия ядросы юк.

ВКП(б) ның Өлкә Комитеты һәм аның бүлекләре түбәнге оешмаларга җитәкчелекне, һич шиксез, яхшыртырга тиеш. Ләкин кайбер бүлекләр, мәсәлән, хәрби бүлек, райкомнарга кәгазь генә җитәкчелек итәләр. Кадрлар бүлегенең дә эше күбесенчә анкеталар тутыруга кайтып кала. Бу бүлек үз эшен гомумән җанландырырга тиеш.

Кадрларга Сталинча кайгыртучанлык күрсәтергә

ВКП(б) Өлкә Комитетының кадрлар бүлеге мөдире урынбасары иптәш Постнова речennән

Партиянең Татарстан оешмасы ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарлары нигезендә кадрларны сайлап алу, күтәрү һәм тәрбияләү буенча шактый эшләр башкарды. ВКП(б) ның Өлкә, шәһәр һәм район комитетларында кадрлар бүлекләре төзелгәннән соң кадрларны өйрәнү һәм урнаштыру эше сизелерлек рәвештә яхшырды. Хәзер кадрлар бүлеге работникларны анкеталар һәм биографияләр буенча гына белү белән генә чикләнмичә, бәлки аларның үзләре белән беседа үткәрә, аларның эшен һәм кимчелекләрен эшкә сәләтле булуларын өйрәнә. Кешеләрне болай өйрәнү аларны җаваплы постка кую мәсьәләсен дөрес хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Шуның белән бергә әйтергә кирәк, өлкә, шәһәр һәм район комитетларының кадрлар бүлекләренең эшендә тагын да җитешсезлекләр бар әле. Кайбер райкомнарның һәм оешмаларның җитәкчеләре кадрларны сайлап алганда һәм аны күтәргәндә дә мөһим мәсьәләгә ул кадәр җиңел карыйлар. Менә берничә мисал. Партиянең Саба райкомы МТС директоры итеп берәүне раслый һәм аңа яхшы характеристика төзеп, Өлкә Комитетка җибәрә. Өлкә Комитетта аның эшен ныклап тикшерә башлагач, ул Заготлененың Шәмәрдән бүлегендә эшне таркау хәлгә төшергән өчен эшеннән алынган кеше булып чыга. Акташ райкомы МТС директорының политик эшләр буенча урынбасары итеп күтәрү өчен бер кешене Өлкә Комитетка раслауга кертә. Тикшерү һәм аның үзе белән беседа үткәрү нәтиҗәсендә аның суд тарафыннан төзәтү эшенә тартылганлыгы ачылды. Югары Ослан райкомы да кадрларны күтәрү эшенә шулай ук җиңел карый. Райпотребсоюзның хәзерләүләр конторасына мөдир итеп күрсәтелгән кешенең характеристикасында, аның дәүләткә каршы настроениедә булганлыгы, бу турыда райкомның карарларында да күрсәтелгәнлеге, аның хөкем ителгәнлеге языла. Шуңа карамастан, райком бу кешене күтәрергә лаеклы дип таба. Менә бу фактлар кадрларны сайлап алуга җиңел карауны ачык күрсәтәләр.

Безнең кадрлар бүлекләренең эшендә тагын бер җидди кимчелек бар. Еш кына, кадрлар тегеяки бу эшкә күтәрелә, аннан соң аны онталар. Кадрларны урнаштыру турында карар кабул итү белән эш бетми, җитәкчелеккә күтәрелгән иптәшнең практик эшенә һәм аның политик үсешенә көндәлек булышлык күрсәтергә,

аның эшенә еш контроль ясарга, кимчелекләрен вактында ачарга һәм аларны төзәтү өчен тиешле чараны күрергә кирәк. Тегеяки бу иптәшне күтәргәндә: „...иптәш политик тотнаклы, активтер белән „файдалана" дип языла. Ә 3—4 айдан бу үсеп килә торган кеше, „эшне башкара алмаганлыктан" дигән сылтау белән эштән алу фактлары була.

Бездә райкомнар эш кына хуҗалык оешмалары җитәкчеләренең инициативасына юл калдырмыйлар, кадрларны сайлап алу, урнаштыру һәм тәрбияләү өчен алардан җаваплылыкны алалар. Мәсәлән, күп кенә райкомнар колхоз председательләрен башта үзләре раслаганнар, ә райзо һәм МТС җитәкчеләре бу турыда соңыннан гына белгәннәр. Дөреслектә исә бу эшне башта алар карарга тиешләр иде.

Кадрлар мәсьәләсендә менә мондый кимчелекләрне кабатламаска, ВКП(б) ның XVIII нче съезды күрсәтмәләрен тулы үтәргә кирәк.

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI нче ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ КӨНДӘЛЕГЕ

12 НЧЕ МАРТ, ИРТӘНГЕ УТЫРЫШ

ВКП(б) Өлкә Комитетының һәм Ревизия Комиссиясенең отчетлары буенча фикер алышулар дәвам итте.

Председательлек итүче иптәш **Мөхаметов** ВКП(б) ның Тымытык райкомының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире иптәш **Миңгалиевкә** сүз бирә. Аның артыннан **Морозов** (Татарстан Эчке Эшләр Халык Комиссары), **Хәмидуллин** (Азнакай райкомы секретаре), **Никишкин** (Наркомзагның Татарстан АССР буенча вәкиле), **Алешков** (Яңа Чишмә райкомы секретаре), **Жуков** (ВКП(б) Өлкә Комитетының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире), **Васильев** (Алексеевский райкомы секретаре), **Абдульманов** (Ит-сөт промышленносте наркомы), **Бусарев** (Теләче райкомы секретаре), **Саланов** (ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире) һәм **Әхметшина** („Азат Хатын" журналы редакторы) иптәшләр чыгып сөйләделәр.

12 НЧЕ МАРТ, КИЧКЕ УТЫРЫШ

Кичке утырыш иптәш **Долатказин** председательлеге астында барды. ВКП(б) Өлкә Комитетының һәм Ревизия Комиссиясенең отчетлары буенча фикер алышулар дәвам итә.

Сүз иптәш **Филимоновка** бирелә. Ул, үзенең чыгышында Татнаркомместпромның үткән елгы планын 100,2 процентка үтәү белән бер рәттән, тулай йомгак канәгатьләнмәслек булуны әйтте. Наркоматның киң куллану товарлары җитештерү планын үтәмәвен һәм эшләнеп чыгу бәясен 5 процентка киметү планын үтәмәвен күрсәтә. Аерым предприятиеләрнең (Татполиграф, пыяла заводы һ. б.) өзеклек белән эшләүләренә, район промышленностена җирле оешмаларның игътибар биреп җиткермәүләренә туктала.

Куйбышев райкомы секретаре иптәш **Вахрушев** партиягә кабул ителгәннәр арасында төп профессияләрдә эшләүчеләр һәм хатын-кызлар аз булуны күрсәтеп, ВКП(б) Өлкә Комитетының оештыру-инструкторлык, кадрлар һәм пропаганда бүлекләренең җитәкчелегендәге төп кимчелекләргә тукталып болай ди:

— Кадрлар бүлеге кешеләрне күбесенчә анкеталар буенча гына өйрәнә. Инструкторлар аерым хәлләрдә маглүматлар җыеп китү белән генә чикләнәләр, ә лекторлар үзләренең килүләре турында бер генә көн элек хәбәр итәләр. Лекциягә чакырылган кешеләр саны күпме була, аларның хәзерлекләре ничек, ул турыда лекторлар һич кызыксынмыйлар. Күпме кеше килде, шуның белән үткәрәләр дә, тизрәк башка районга китү ягын карыйлар.

Кичке утырышта Татарстан Халык Комиссарлары Советы Председателе иптәш **Гафиятуллин** зур речь белән чыкты. Ул Өлкә Комитетының эшенә тукталып, Өлкә Комитеты бүлекләренең, секторларының һәм инструкторларының әле райкомнарга булышлык күрсәтергә өйрәнеп җитмәгәнлекләрен әйтеп үтте. Кадрлар сайлап алу мәсьәләсенең гаят җидди эш булуын, җаваплы эшләргә меңнәрчә яңа, эшлекле кадрлар күтәрелүне конкрет фактлар белән күрсәтте. Кайбер урыннарда (Тәтеш, Актаныш, Арча райкомнарында, Совнаркомда, Наркомземда) кадрлар сайлап алуга өстән, җавапсыз карау факсларын китерде.

Авыл хуҗалыгы мәсьәләләренә күчеп, иптәш **Гафиятуллин** Татсовнаркомның һәм Татнаркомземның кайбер җаваплы работниклары иген уңышы һәм терлекчелек мәсьәләләре буенча артта калган настроениене куәтләү белән чирләгәнлекләрен әйтеп, мондый настроениеләргә каты отпор бирергә кирәклеген күрсәтте.

Татнаркомздрав эше турында:

— Анда иң төп нәрсә аксый: кадрлар турында кайгыртучанлык күрсәтү юк һәм кадрлар белән эшләү җитәрлек түгел,—ди. Наркомместпром эшенә тирән анализ ясаганнан соң, иптәш **Гафиятуллин** наркоматның эшен ничек яхшырту буенча конкрет юллар күрсәтте, өзеклектәге предприятиене алга чыгаруда, аңа аппаратның бөтен көче белән булышлык итәргә, юллар күрсәтергә; искечә эшләүдән, җитешсезлекләргә регистрация ясап утырудан, өзеклек турында бер буйдан сөйләнүдән туктап, заводларга конкрет ярдәм итәргә кирәклеген әйтте.

Төзелеш работнигы иптәш **Ястребелов** Татарстанда яңа төзелешләр өчен үтә әһәмиятле материалларны җитештерү эше әле дә булса тиешенчә юлга салынмауны күрсәтте.

— Безгә иң кирәкле һәм җитешми торган төзү материалларын ерактан китертүдән арынырга, аларны үзебездә, Татарстанда җитештерергә кирәк, ди.

Мамадыш райкомы секретаре иптәш **Белоглазов** райондагы 3 совхоз, МТС, спирт заводы, Соколка рейде кебек предприятиеләрнең эшчеләре хисабына партия оешмасының үсеше йомшак булуы турында сөйләде. Аннан соң ул кадрлар сайлап алуда шактый уңышларга ирешелүе, 434 кешенең җаваплы постларга күтәрелүе турында әйтеп үтте. Җаваплы эшләргә күтәрелүчеләрнең 34 проценты хатын-кызлар, ди. Сайлаулардан соң авыл советлары депутатларының сайлаучылар белән элемтәсе яхшырганлыкны, сайлаучылар алдында отчет бирүләр тәртипкә салынганлыгын күрсәтте.

Иптәш **Пичугин** үзенең чыгышында Казан тимер юлының канәгатьләнмәслек эшләве белән килешсә дә, Өлкә Комитеты отчетында тәнкыйть ителүгә зур ризасызлык күрсәтте. Соңгы вакыттагы аерым уңышлар белән юл эшендәге зур кимчелекләрне сылап калдырырга маташты. Шуның өчен делегатларның:

— Сезне мактарга гына кирәк икән, иптәш начальник, дип репликалар ташлаулары бик урынлы иде.

Кичке утырышта тагын **Перов** (Татарстан прокуроры) һәм **Мандур** (Казан тимер юлының политбүлек начальнигы) иптәшләр чыгып сөйләделәр.

Зал бер минутка тынлыкта кала. Залга бөек җиңүләр белән дан алган, бөтен халык мәхәббәте белән чолгап алынган Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең Казан гарнизоны вәкилләре керә. Конференция аларны аяк өсте басып каршы ала. Залда: „Яшәсен героик Кызыл Армия!", „Яшәсен бөек Сталин!" тавышлар яңгырый...

Чит илләрдә

Сугышның алты ае турында Германия армиясе верховный командованиесенең сводкасы

Германия информация бюросы сугышның беренче алты аенда булган сугыш хәрәкәтләре турында Германия армиясе верховный командованиесенең сводкасын игълан итте.

Сводкада болай диелә:

„Германия армиясе Польшага каршы булган 18 көнлек сугыш походында Польшаның коралллы көчләрен тар-мар итте һәм Германия белән Совет арасындагы чиккә кадәр Польша дәүләте территориясен алды.

Германия гаскәрләре планга туры китереп Зигфрид линиясендәге позицияләргә урнаштылар һәм бу линия Төньяк диңгез ярларына кадәр озайтылды. Дошман Зигфрид линиясенә һөҗүм итәргә генә түгел, хәтта Германиянең андагы ныгытмаларының берсенә дә якын килергә батырчылык итмәде. Германиянең разведка һәм удар отрядлары бәрелешләрдә югары сугышчан сыйфатлар һәм югары техника күрсәттеләр. Дошман беренче оборона линиясе полосасына үтеп керергә маташкан урыннарда, Германия частьләре кискен контратакалар белән аны элекке позицияләренә алып ташладылар.

Германиянең хәрби диңгез флоты, Польша флотын юк итеп, Англиянең һәм Франциянең хәрби флотларына каршы уңышлы операцияләр башлады.

Төньяк диңгездә Германия флотына Германия суларында йөзү куркынычсызлыгын һәм Германия сәүдә пароходчылыгын саклауны тәэмин итү белән бергә, дошманның сәүдә пароходчылыгына каршы сугыш алып бару бурычы да йөкләтелгән иде. Бу сугышта Германия флотының су өсте һәм су асты көчләре катнаштылар. Бер үк вакытта Англиянең көнчыгыш һәм көнбатыш ярларына мина атакалары да кулланылды. Атлантика океанында Германиянең „Адмирал граф Шпее“ линкоры һәм „Дейчланд“ линкоры операцияләр алып бардылар. Атлантика океанының төньяк өлешендә Германиянең эре хәрби диңгез көчләренең операцияләре нәтиҗәсендә дошман гаять зур югалтуларга дучар ителде. Германиянең сугыш караблары дошманның түбәндәге сугыш корабларын: „Ройял Ок“ линкорын, „Корейджес“ авианосецын, „Роуалпинди“ ярдәмче крейсерын, сигез эсминецын („Бланш“, „Джипси“, „Дачесс“, „Гренвиль“, „Эксмаус“, „Виконот“, „Дэринг“ һәм „Джерси“ эсминецларын) юк иттеләр. Шулай ук, авиация һәм су асты көймәләре ярдәме белән, төрле класстагы башка 20 сугыш караблары (сакчылык караблары, мина тральщиклары, су асты көймәләре һәм башкалар) батырылды. Англия флотының флагман карабы „Нельсон“ линкоры, „Бархэм“ линкоры, „Рипалс“ линкоры, авыр „Эксетер“ крейсеры, авыр „Бельфаст“ крейсеры һәм күп кенә эсминецлар, сакчылык караблары һәм су асты көймәләре бик нык зарарландылар. Шул ук вакыт эчендә Германиянең хәрби диңгез көчләре дошманның һәм нейтраль илләрнең Англия сугыш караблары күзәтчелегендә алып барыла торган 1.104.913 брутто-регистро-тонна авырлыгындагы 532 пароходын батырдылар.

Бу югалтуларга чагыштырганда, Германия флотының үзенең югалтулары зур булмады. Германия бер линкорын, ике эсминецын, алты сакчылык карабын һәм мина тральщикларын һәм 11 су асты көймәсен югалтты.

Германия авиациясе Польшага каршы булган походта актив катнашты. Польша авиациясенә каршы булган хәрәкәтләр белән бер үк вакытта Германия авиациясе көнбатышта да актив хәрәкәтләр алып барды. Германия самолетлары, һава шартлары начар булган вакытларда да, еш кына Англия һәм Франция өстендә еракка разведка очышлары үткәрделәр. Германия самолетлары Оркней һәм Шотландия атауларына кадәр барып җиттеләр.

Безнең самолетлар дошманның хәрби диңгез көчләренә, сугыш караблары сакчылыгында бара торган коралланган сәүдә пароходларына һәм судно лар караваннарына берничә тапкыр һөҗүм иттеләр. Бу һөҗүмнәр вакытында 75 мең брутто-регистротонна авырлыгындагы 65 пароход батырылды. Сүз, күп кенә хәлләрдә, дошман пароходлары турында яки нейтраль илләрнең Англия өчен йөк төягән пароходлары турында бара.

Сугыш хәрәкәтләренең алты ае эчендә Англиянең һәм Франциянең 285 самолеты бәреп төшерелде. Дошман авиациясенең бу югалтуларына Англиянең батырылган авианосецындагы 50 самолетны да өстәргә кирәк. Шулай итеп, сугыш игълан ителгәннән бирле көнбатыш державаларының бәреп төшерелгән һәм һәлак ителгән самолетларының саны кимендә 335 кә җитә. Болардан тыш, дошманның тагылмалы 9 аэростаты бәреп төшерелде.

Германия авиациясе сугышның алты ае эчендә барлыгы 35 самолетын югалтты һәм 8 самолеты авария нәтиҗәсендә һәлак булды. Димәк Германия авиациясе барлыгы 43 самолет югалткан“.

11 март. (ТАСС).

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА. Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә 9 нчы мартта Наньнинннан төньяктарак артиллериядән көчле атышулар булган.

Кытай гаскәрләре японнарны Сватоудан төньяк Чаньхайның көньяк-көнчыгыш тирәсеннән кысрыклауны дәвам иттерәләр. Бу районда 9 нчы мартта кытайлар японнарны позицияләреннән кысрыклап чыгарганнар.

Кытай гаскәрләре өстәмә көчләр алып 9 нчы мартта Макадан төньяктарак Шицизи секторында японнар позициясенә һөҗүм иттеләр. Кытайлар японнарның оборона линиясе аркылы үтеп, шәһәргә керделәр, шәһәрдә берничә сәгатьләр буена каты сугышлар барды. Соңыннан кытайлар шәһәрдән кысрыклап чыгарылганнар.

ҮЗӘК КЫТАЙДА. Ханчжоу—Цзясин—Хучжоу шоссе юлы буенча кытай частьләреннән актив операцияләр күренә.

Хэнань провинциясенең көньяк өлешендә Синьян районында актив хәрәкәтләр дәвам итә. Японнар монда яңа көчләр алганнар һәм кытайларга каршы сугыш алып баралар.

Японнарның Янцзы елгасыннан бара торган канонеркаларына Дунлю районында (Аньхуэй провинциясе) 10 нчы мартта кытай артиллериясе ут ачкан.

Япония ялчылары арасында ызгыш

ЧУНЦИН, 11 март. (ТАСС). Кытай матбугаты Японияннең Кытайдагы власть кешеләреннең яңа уңышсызлыклары турында хәбәр итә. „Ортодоксаль Гоминдан“ (яки Ван Цзин-вей тарафдарлары) дигән оешманың „башкарма комитеты“ ның 6 нчы мартта булачак пленумы апрельгә кичектерелгән. Шулай итеп Бэйпиндагы курчак „хөкүмәт“ башлыгы Ван Кэ-мин Нанкинга килмәгән. Аның урынына Ху Лю-гуан килгән. Курчак хөкүмәт кешеләре арасындагы мәсьәләләр Кытайда Ван Цзин-вей „хөкүмәте“ „үзәк хөкүмәт“ төзүе өчен. Генерал У Пей-фу урынына төньяк генераллары Ци Се-юаньның курчак гаскәрләре. Алар аңа шулай ук Ван Кэ-мин урынына „Бэйпин хөкүмәте“ башлыгы булуны да тапшырмакчы булалар, чөнки алар Ван Кэ-минга ышанмый башладылар. Японияннең башка генераллары—Кытайның дошманнары — Ци Се-юаньны Ван Кэ-мин урынына куярга тырышалар. Японияннең Кытайдагы махсус служба җитәкчеләреннән берсе Сакинисидә Ван Цзин-вейгә каршы тора. „Үзәк хөкүмәтнең“ составына генерал Цзинь Юнь-пинне күрсәтә. Төньяктагы япон генералларының берсенең җитәкчелегендә „үзәк хөкүмәт“ төзергә маташалар. Ван Кэ-мин белән Ван Цзин-вей арасында да дошманлык бетмәгән иде.

СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШНЫ ТАГЫН ДА КИҢРӘК ҖӘЕЛДЕРЕРБЕЗ

Саба райпотребсоюзы узган ел товар әйләнеше планын 117,6 процент итеп үтәде. Кооперациягә яңа членнар тарту, пай җыю, җәмагать туклануы өлкәсендә һәм авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү буенча да яхшы гына уңышларга иреште. Саба сельпосының Тимершык авылындагы кибет мөдире иптәш Юнусов, Шәкше сельмагы мөдире Минһаҗев, Урта Саба кибете мөдире Заһидуллин, Иске Икшермә сельпосында Галиуллин, Сабирҗанов, Утар сельпосында Зарипов иптәшләр еллык планны 15—25 процент арттырып үтәделәр һәм хәзер дә алда баруларында дәвам итәләр.

Райпотребсоюз быел язгы чәчү вактында колхоз производствосы өчен кирәк булган товарлар белән тоткарсыз рәвештә сәүдә итүне тәэмин итү өчен барлык чараларны күрә. Бүгенге көндә барлыгы 120 мең сумлык товар кайтартылды һәм сельполарга бүлеп бирелде. Ул товарлар арасында: арба, сука тимере, бау, кыр кухнясе, игәү, камыт, радио кирәк-яраклары, майлау материаллары һәм башка төрле товарлар бар.

Без быел райондагы производство артельләрендә җитештерелә торган киң куллану товарлары белән еллык товар әйләнеше планының кимендә 20 процентын күләмендә сәүдә итүне, хуҗалык расходларын 20 процентка кыскартуны һәм 1 нче августка кадәр агымдагы ремонтларны тулысынча төгәлләүне бурыч итеп куйдык.

Орденлы республикабызның XX еллыгы исемендәге социалистик ярышны тагын да киңрәк җәелдереп, бу бурычларны намус белән үтәрбез.

А. Хәбиб.

Саба райпотребсоюзы председателе.

КАЗАНДА А. М. ГОРЬКИЙ МУЗЕЙ-ЙОРТЫ АЧЫЛДЫ

Казанда кичә, 12 нче мартта, пролетариатның бөек язучысы Алексей Максимович Горький музей-йорты ачылды. Музей Галактионов урамында, элек Деренков булочные һәм пекарнясе булган йортта („Динамо“ стадионы янында), урнашкан. 1885—86 нчы елларда А. М. Горький шушы йортта торган һәм шул ук йортның подвалындагы пекарняда пекарь ярдәмчесе булып эшләгән.

Йорт элеккеге хәленә китерелде. Йортның подвалы Горькийның „Минем университетларым“ дигән әсәрендә язылганча җиһазландырылган.

Йортның икенче катында музей залы урнашкан. Анда А. М. Горькийның Казандагы тормышы (1884—1887 нче еллар) турында документлар, фото-рәсемнәр, скульптуралар куелган. Бер почмакта иске Казан күренеше һәм Горький яшәгән елларда Казан шәһәренең планы куелган һәм Горькийның Казан турында язылган сүзләре язып куелган. Экспонатлар арасында Казан скульптуры К. С. Счастьнев тарафыннан эшләнгән „Булочник-пропагандист“ дигән скульптура, Горькийның генеральша Корнэда бакчачы булып эшләгән вактын күрсәткән „Горький—бакчачы“ дигән рәсем, Горькийның Казанда кайларга булки ташуын күрсәткән һәм аның үзе тарафыннан билгеләр куелган план, „Добрый“ пароходының макеты, Горькийның 1928 нче елны Казан краеведы иптәш Калининга язган хатлары һәм башкалар бар.

Музей-йортта болардан башка да күп кенә кызыклы документлар, фото-рәсемнәр һәм башка экспонатлар бар.

Казан шәһәре предприятиеләреннән, уку йортларыннан һәм мәктәпләрдән музейгә экскурсияләр оештыру турында заявкалар алына башлады.

Р. Н.

АСТРОНОМИЯ ҖӘМГЫЯТЕНДӘ

Татарстан Астрономия җәмгыятенең шушы көннәрдә отчет-сайлау җыелышы булып үтте. Правление председателе профессор И. А. Дюков җәмгыятнең эше турында отчет докладе ясады. Отчет чоры эчендә җәмгыятнең членнар саны ике тапкыр арткан. Хәзер анда 66 кеше член булып тора. Астрономия темалары белән барлыгы 8 гомуми җыелыш үткәрелгән. 4 урта мәктәптә яшь астрономнар секцияләре оештырылган. Бу секцияләргә 80 ләп укучы тартылган. Шул ук вакытта эштә зур гына җитешсезлекләр дә булган. Казан Дәүләт университетында студентларның астрономия секциясе, Казан Юридик институтындагы һәм Зеленодольский шәһәрендәге секцияләр йомшак эшләгәннәр.

Җыелыш правлениенең эшен гомумән алганда канәгатьләнерлек дип тапты һәм эштәге җитешсезлекләрне ашыгыч бетерергә кирәклекне күрсәтте. Җыелышта катнашучылар 1941 нче елда булачак кояш тотылуны күзәтүгә ныклы хәзерлек алып барырга кирәклекне әйттеләр.

Астрономия җәмгыятенең яңа правлениесе составына И. А. Дюков, Хәбибуллин, Н. П. Макаров, Л. Я. Ананьева, Шабалин, Кадомский, Зюко иптәшләр, кандидатлар итеп Кузнецов, Хапаев иптәшләр, ревизия комиссиясенә доктор С. Т. Вельховер, В. А. Александров, Нечаев иптәшләр сайландылар.

В. Александров.

СССР ның Памирдагы чиге. РӘСЕМДӘ: лейтенант Тишин һәм кече командир Смирнов иптәшләр дозорда.

В. Шаховский фотосы (ТАСС фото-клишесе).

Татарстанның XX еллыгына хәзерлек

Йөкләмәләр үтәлә

„Спартак“ комбинаты коллективы соңгы вакытларда үзенең эшен шактый яхшырта төште. Коллектив мехчылар чакыруына зур күтәренкелек белән кушылды һәм ярты еллык планны орденлы республикабызның XX еллыгына—25 нче июньгә үтәү йөкләмәсен алды.

Йөкләмәләр практик эш белән ныгытыла. Комбинатыбызның мактаулы кешеләре—стахановчылар һәм ударниклар хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә яхшы күрсәткечләр бирәләр.

Мәсәлән, хром заводында эшләүче Голубев, Мөхәммәтҗанов, Әхмәтҗанов, Солнцева, Кузнецова, Җәләева, Миңнеханова, кисү цехында Буткина, Фирцова, Ильин, унтовый цехта Макеева, Шәрифуллин, Закамский һәм йөзләрчә башка иптәшләр айлык план үтәлешен 200—250 процентттан киметмиләр. Нәтиҗәдә, бу алдынгылар январь-февраль айлары планын гомумән комбинат буенча уртача 100,4 процент итеп үтәүне тәэмин иттеләр.

Комбинатның утиль цехы аеруча яхшы эшли. Ул үзенең январь ае планын 187,4 процентка һәм февраль ае планын 143,8 процентка үтәде.

Уйлап табуга, рационализация чараларына зур урын бирелә. Узган елны гына да комбинат стахановчыларыннан һәм инженер-техник работникларыннан 117 рационализаторлык тәкъдимнәре алынды. Шулардан 62 тәкъдимне тормышка ашыру комбинатка 610 мең сум экономия ясау мөмкинлеген бирде. Кабул ителгән һәм файдалы дип табылган башка тәкъдимнәрне дә якын арада тормышка ашыру буенча практик чаралар күрелә. Алардан без тагын да 619 мең сумлык экономия алачакбыз.

Шик юк, стахановчылык хәрәкәтен тагын да киңәйтеп, республикабызның данлыклы юбилеен зур казанышлар белән билгеләячәкбез.

Х. Мусина.

ТАССР Верховный Советы депутаты.

Социалистик ярыш алдынгылары

М. Горький исемендәге завод коллективы Татарстанның XX еллыгын производствода зур уңышлар белән каршылау өчен яңа йөкләмәләр алган иде. Алган йөкләмәләрне уңышлы үтәү өчен цехлар, сменалар, участкылар һәм бригадалар арасында ярыш договорлары яңартып төзелде. Хәзер бу йөкләмәләр конкрет эш белән ныгытыла.

Колчин, Смирнович, Дьячков иптәшләр җитәкчелек итә торган цехларда февраль ае планы 23 нче числода ук үтәлде. Иптәш Смирнович җитәкчелек итә торган кызыл байраклы цех коллективы ярышта иң алдынгы сафта бара. Цехның алдынгы стахановчылары яңа нормаларны яхшы үзләштерделәр. Макеев, Никифоров иптәшләр җитәкчелек итә торган бригадалар көнлек заданиене 190—200 процент итеп үтиләр. Бу цехта берничә профессияне үзләштерүчеләр саны да көннән-көн арта. Иптәш Колчин җитәкчелек итә торган цехта ике станокта эшләүче иптәш Коньков көнлек норманы 260—270 процент итеп, 3 станокта эшләүче иптәш Насыйров 340—350 процент итеп үтиләр.

Завод коллективы февраль ае планын арттырып үтәде.

Б. Камалов.

ЧАЙКОВСКИЙ ЮБИЛЕЕ АЛДЫННАН

Казан элемтәчеләр клубының иптәш Трофимов җитәкчелегендәге хоры русның бөек композиторы П. И. Чайковскийның 100 еллык юбилеенә хәзерләнә.

Юбилей көннәрендә бу коллектив элемтәчеләр клубында, Кызыл Армия йортында һәм радио аркылы Чайковский программасы белән концертлар бирәчәк. Хәзер коллектив Чайковскийның „Евгений Онегин“ операсыннан крестьяннәр хорын, „Черевички“ операсыннан „Ой кто хочет меду пить“ һәм башкаларны өйрәнә. Коллективның күренекле солистларыннан Николаева, Семенова, Ламинский һәм башкалар Чайковскийның романсларыннан аерым номерлар хәзерлиләр.

Иң яхшы телеграф исемен алу өчен ярыш

Телеграф работникларының Бөтенсоюз киңәшмәсе СССР да иң яхшы телеграф исемен алу өчен ярыш оештырырга карар кабул иткән иде. Бу ярыш 1940 нчы елның 1 нче апреленнән 1 нче октябренә кадәр дәвам итәчәк. Анда катнашу өчен Казан Үзәк Телеграфында хәзерлек башланды. Моның өчен элемтә работниклары союзының Татарстан Өлкә Комитеты президиум членнарына аерым заданиеләр бирде. Хәзер телеграфта сменалар һәм работниклар арасында социалистик ярыш киң колач алды.

БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ ДЕКАДАСЫ БАШЛАНДЫ

9 нчы мартта язучыларның Г. Тукай исемендәге кабинетында зур әдәби кичә белән балалар әдәбияты декадасы башланды. Кичәдә балалар әдәбиятының торышы турында тәнкыйтьче Хәсән Хәйри иптәшнең докладе тыңланды.

Балалар әдәбияты декадасын башлап җибәрүгә багышланган бу кичәдә татар совет язучылары һәм шагыйрьләре үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Кичәдә гармончы Фәйзи иптәш Биккинин үзенең гармоннарында татар совет композиторларының балалар өчен язылган көйләрен уйнады. Җырчы Камаева нәниләр өчен булган җырларны зур осталык белән башкарды.

Декада барышында пионерлар һәм мәктәп балалары йортында, шулай ук мәктәпләрдә әдәби кичәләр үткәрелә. Декада уңае белән язучыларның Г. Тукай исемендәге кабинетында „Татар совет балалар әдәбияты“ дигән темада әдәби күргәзмә оештырылды. Күргәзмәгә татар совет балалар әдәбияты әсәрләре, балалар әдәбияты язучыларының портретлары, совет балалар әдәбиятына багышланып чыккан мәкаләләр куелган.

А. Гомәр.

БЕЛДЕРҮЛӘР

— 13 нче март, кич 6 сәгатьтә Партия Мәгарифе йортында (Чернышевский урамы, 25) шәһәр комсомол активы өчен лекция була. Тема: „Ленин—Сталин партиясе—Бөек Октябрь Социалистик революциясенең юлбашчысы һәм оештыручысы. Лектор—иптәш Звонкович.

— 13 нче март, кич 7 сәгатьтә Казан Дәүләт университетының 1 нче аудиториясендә, Молотов районы өчен лекция үткәрелә. Тема: „Кытайда Японияннең империалистик сугышы һәм Кытай халкының үзенең бәйсезлеге өчен көрәше“. Лектор—иптәш Тимофеев.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 13 нче мартта театрның ял көне.
14 нче мартта
ЛЕНИН
Талоннар белән кертелми.
Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 13 нче мартта
ШӘМСЕКАМӘР
Талон 134.
Иртәгә, 14 нче мартта
КҮЗЛӘР Талон 135.
Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген, 13 нче мартта, данлыклы
ЗОЛЛО ТИМЕР ЮЛЫ
300 хайван һәм кошлар катнаша һәм башка күп номерлар.
РСФСР ның атказанган артисты орденлы
М. ЗОЛЛОның
соңгы гастрольләренә билетлар сатыла.
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Зур драма театры бинасында.
Бүген, 13 нче мартта
ФАУСТ
Талон 87. Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 20—04 телефоны буенча заявкалар алына.

„ГЛАВКИНОПРОКАТ“ НЫҢ ТАТАРСТАН БҮЛЕГЕ
якын көннәрдә Татарстан АССР кино-экраннарына, „Союздетфильм“ дә эшләнгән

В. Поташов сценарийсы. Режиссер А. Разумный.
Фильм мәктәптә коллективизм идеясен күрсәтә.
исемле тавышлы, художестволы яңа фильм бирә.

Подписчиклар игътибарына!
КОГИЗ ның подпискалар алу конторасы
Бауман урамына (Матбугат йортына)
КОГИЗ ның 1 нче магазинына
КҮЧТЕ
434—2—1

Машиналар төзү заводы
җиңел һәм йөк автомобильләре
сатып ала
41—54 һәм 16—22 телефоннары буенча яисә почта адресы буенча М. Ф. Шиховка мөрәҗәгать итәргә. 36 нчы почта бүлеге, почта ящиге 732.
373—5—4

КИРӘК:
ТатТАСС редакциясендә эшләү өчен, ТАТАР һәм РУС ТЕЛЛӘРЕН БЕЛҮЧЕ СТЕНОГРАФИСТКА. Бауман урамы, Матбугат йорты, 3 нче кат, 52 нче бүлмә.
446—3—2

Серго Орджоникидзе исемендәге заводка югары КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ ОБОЙЧЫЛАР һәм СТЕНОГРАФИСТЛАР. Заводның кадрлар бүлегенә килергә.
459—4—1

„Главлегснаб“ ның Казан бүлегенә даими эшкә СЕКРЕТАРЬ-МАШИНИСТКА, БУХГАЛТЕР, КАРТОТЕКАЧЫ, ӨСТӘМӘ МАТЕРИАЛЛАР БУЕНЧА ТОВАР БЕЛГЕЧЕ (күн товарлар һәм эш киемнәре белән таныш кеше), АГАЧ ХИМИКАТЛАРЫ ХӘЗЕРЛӘҮ һәм ҖИҺАЗЛАУ МАТЕРИАЛЛАРЫ БУЕНЧА ТОВАР БЕЛГЕЧЕ. Казан, Кече Ямашев урамы, 71.
462—1

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы, яңа фильм ТАШЛАНДЫК
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ПРЕМЬЕРА ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8 һәм 10 да	ЯШӘРГӘ
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	УТ ТРАНСПОРТЫ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	УКЫТУЧЫ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ПАТРИОТ

„Трансэнергокадр“ ның КАЗАН АВТОМӘКТӘБЕ
производстводан аерып һәм аермыйча укытып III нче класс шоферлар хәзерләү, шулай ук III һәм II нче класс шоферларның квалификацияләрен күтәрү курсларына шушы ел 15 нче мартттан
УКУЧЫЛАР АЛА
Укучылар предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм башка оешмалардан бирелгән командировка белән алыналар. Казан, Банк урамы, 15.
467—2—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А —754   ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА. ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД.   ЗАКАЗ № 983.